ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27. 04. 2018 г.Мензелинск № 487

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елдагы “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында”гы №182 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.04.2018 елдагы “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елдагы “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында”гы №182 карарына үзгәрешләр кертү турында”гы №281 карары нигезендә

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1.Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары күләме 11 163 сум булган авыл җирлегендәге муниципаль хезмәт вазифаларының кече төркеме белгеченең вазифаи оклады күләмен кабатлап исәпләнә.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең,

муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыруның беркетелгән нормативлары;

Кушымта №1-3 нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча авыл җирлекләренең, шәһәр җирлекләренең, муниципаль районның муниципаль хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентларын;

Кушымта №4-5 нигезендә, Минзәлә муниципаль районының контроль-исәп органы рәисенең, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының авыл һәм шәһәр җирлекләрендә, муниципаль районда үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланган вазифаи затларының, депутатларның, муниципаль берәмлек Башлыгының айлык акчалата бүләкләве күләмен.

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары күләменең, шулай ук айлык һәм башка өстәмә өстәп түләүләр һәм бирүләр күләменең арттыру ягына тулы бер сумга түгәрәкләнергә тиешлеген билгеләргә.

4. Түбәндәгеләрне көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 30.12.2018 елдагы "Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә айлык һәм башка өстәмә өстәп түләүләр күләмен билгеләү, аларны башкару тәртибе турында"гы №834 карарын;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 10.06.2009 елдагы "30.12.2018 елдагы "Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә айлык һәм башка өстәмә өстәп түләүләр күләмен билгеләү, аларны башкару тәртибе турында"гы №834 карарына үзгәрешләр кертү турында"гы №427 карарын;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 17.10.2012 елдагы "Минзәлә муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазифаи окладларын һәм җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, депутатларның, муниципаль берәмлек башлыкларының акчалата бүләкләве күләмен индексацияләү турында"гы № 1182 карарын;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 10.10.2013 елдагы "Минзәлә муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазифаи окладларын һәм контроль-исәп палаталары рәисләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, депутатларның, муниципаль

берәмлек башлыкларының акчалата бүләкләве күләмен индексацияләү турында”гы №1015 карарын;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 24.08.2017 елдагы “Минзәлә муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазифаи окладларын һәм контроль-исәп палаталары рәисләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, депутатларның, муниципаль берәмлек башлыкларының акчалата бүләкләве күләмен индексацияләү турында”гы №804 карарын.

5. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылганнан соң 10 көн узгач һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләр таратылганнан соң көченә керә.

6. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет һәм җир-милек мөнәсәбәтләре Рәисе Л.И.Кондратьевага йөкләргә.

Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы В.Р.Гыйләҗетдинов.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Карары белән
Расланган
Дата 24.04.18 № 427

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләрнең, контроль-исәп органы рәисенең, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, депутатларның хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары

Гамәлдәге нормативлар Минзәлә муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләрнең, контроль-исәп органы рәисенең, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, депутатларның хезмәтенә түләүгә чыгымнар күләмен билгелиләр.

## I.Гомуми нигезләмәләр

Муниципаль хезмәткәрләрнең, контроль-исәп органы рәисенең, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, депутатларның, муниципаль берәмлекләр башлыкларының айлык акчалата бүләкләү күләмен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тиешле муниципаль берәмлекнең статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына бәйле рәвештә хезмәткә түләү төркемнәренә түбәндәгечә бүленәләр:

1) республика әһәмиятендәге шәһәр һәм район әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре; шәһәр округлары; республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән, составына шәһәр җирлекләре кергән муниципаль районнар; башка муниципаль районнар:

беренче төркемгә халык саны 1000 меңнән югары булган муниципаль берәмлекләр кертелә;

икенче төркемгә – халык саны 500-1000 мең булган муниципаль берәмлекләр;

өченче төркемгә – халык саны 250-500 мең булган муниципаль берәмлекләр;

дүртенче төркемгә – халык саны 100-250 мең булган муниципаль берәмлекләр;

бишенче төркемгә - халык саны 20-100 мең булган муниципаль берәмлекләр;

алтынчы төркемгә - халык саны 15-20 мең булган муниципаль берәмлекләр;

жиденче төркемгә - халык саны 15 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

сигезенче төркемгә – халык санына бәйсез рәвештә башка муниципаль районнар;

2) шәһәр тибындагы бистәләр нигезендә барлыкка килгән шәһәр җирлекләре һәм авыл җирлекләре:

тугызынчы төркемгә халык саны 10 меңнән артык булган муниципаль берәмлекләр кертелә;

унынчы төркемгә – халык саны 5-10 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

унберенче төркемгә - халык саны 1,5-5 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;

уникенче төркемгә - халык саны 1,5 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләр.

2. Составына шәһәр җирлеге кергән, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән муниципаль районны хезмәткә түләүнең тиешле төркеменә керткәндә, бары тик күрсәтелгән шәһәр җирлеге территориясендә даими яшәүче шәһәр халкы гына исәпкә алына.

3. Составына шәһәр җирлеге кергән, республика әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән муниципаль район гамәлдәге бүлекнең1 нче пункты 1 нче подпунктында каралганга караганда, хезмәткә түләү буенча бер төркемгә югары тора.

## II. Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, Татарстан Республикасы җирле үзидарәсенең сайланган органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-исәп органнары рәисләренең хезмәтенә түләү

4.Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланган органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекнең контроль-исәп органы рәисенең айлык акчалата бүләкләнүе Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 27.04.2018 елдагы "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында"гы № 487 карарына Кушымта №4 һәм №5 күрсәтелгәннән артмаган күләмдә билгеләнә.

5. Муниципаль берәмлекләр башлыкларына, депутатларга, Татарстан Республикасы җирле үзидарәсенең сайланган органнары әгъзаларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-исәп органнары рәисләренә ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү айлык акчалата бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә.

6. Муниципаль берәмлекләр башлыкларына, шәһәр һәм авыл җирлекләре булган һәм хезмәткә түләүнең дүртенче-җиденче, тугызынчы-уникенче төркемнәренә керүче муниципаль берәмлекләрдән тыш, ай саен бирелә торган акчалата бүләкләүдән һәм ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләүдән тыш, өстәмә ай саен акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр бирелергә мөмкин. Шул ук вакытта тиешле муниципаль берәмлек башлыгына акчалата түләүләрнең ай саен гомуми күләме, түбәндәге нисбәттән чыгып, Татарстан Республикасының тиешле дәүләт вазифасын башкаручы затка акчалата түләүләрнең айлык гомуми күләменнән арта алмый:

1) беренче төркемгә кергән муниципаль берәмлек башлыгына акчалата түләүләрнең гомуми күләме Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарына акчалата түләүләрнең бер айлык гомуми күләменнән арта алмый;

2) икенче төркемгә кергән муниципаль берәмлек башлыгына акчалата түләүләрнең гомуми күләме Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарына акчалата түләүләрнең бер айлык гомуми күләменнән арта алмый;

3) өченче-дүртенче төркемгә кергән муниципаль берәмлек башлыгына акчалата түләүләрнең гомуми күләме Татарстан Республикасы министрына акчалата түләүләрнең бер айлык гомуми күләменнән арта алмый;

4) сигезенче төркемгә кергән муниципаль берәмлек башлыгына акчалата түләүләрнең гомуми күләме Татарстан Республикасы министрына акчалата түләүләрнең 0,9 бер айлык гомуми күләменнән арта алмый.

7. Муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына, шәһәр һәм авыл җирлекләре булган һәм дүртенче-җиденче, хезмәткә түләүнең тугызынчы-уникенче төркемнәренә керүче муниципаль берәмлекләрдән тыш, ай саен бирелә торган акчалата бүләкләүдән һәм ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләүдән тыш, өстәмә ай саен акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр бирелергә мөмкин. Шул ук вакытта муниципаль берәмлек башлыкларының күрсәтелгән урынбасарларына акчалата түләүләрнең айлык гомуми күләме тиешле муниципаль

берәмлекләрнең башлыкларына акчалата түләүләрнең 0,55 айлык гомуми күләменнән арта алмый.

8. Муниципаль берәмлекнең контроль-исәп органы рәисенә ай саен бирелә торган акчалата бүләкләүдән һәм ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләүдән тыш, өстәмә ай саен акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр бирелергә мөмкин. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык гомуми күләме тиешле муниципаль берәмлек башлыгына акчалата түләүләрнең 0,55 айлык гомуми күләменнән арта алмый.

9. Шәһәр һәм авыл җирлекләре булган муниципаль берәмлекләр башлыкларының, аларның урынбасарларының хезмәтенә түләү шартларын җайга салучы муниципаль хокукый акт белән айлык акчалата бүләкләү түләү билгеләгәндә, күрсәтелгән затларның ай саен акчалата бүләкләү өлешендә хезмәткә түләү чыгымнары күләме хезмәткә түләүнең дүртенче-алтынчы төркеменә караган муниципаль берәмлек башлыклары өчен елга 11 айлык акчалата бүләкләү нормативыннан арта алмый, хезмәткә түләүнең җиденче төркеменә кертелүчеләр өчен – елга 10,83 айлык акчалата бүләкләү, хезмәткә түләүнең тугызынчы төркеменә кертелүчеләр өчен – елга 7,93 айлык акчалата бүләкләү, хезмәткә түләүнең унынчы төркеменә кертелүчеләр өчен – елга 6,35 айлык акчалата бүләкләү, хезмәткә түләүнең унберенче төркеменә кертелүчеләр өчен – елга 5,55 айлык акчалата бүләкләү, хезмәткә түләүнең уникенче төркеменә кертелүчеләр өчен – елга 4,65 айлык акчалата бүләкләү;
аларның урынбасарлары өчен - хезмәткә түләүнең дүртенче-унберенче төркеменә кертелүчеләр – елга 8 айлык акчалата бүләкләү, аларның урынбасарлары өчен – хезмәткә түләүнең уникенче төркеменә кертелүчеләр – елга 6,64 айлык акчалата бүләкләү.

10. Шәһәр һәм авыл җирлекләре булган муниципаль берәмлекләрнең башлыкларының, аларның урынбасарларының түләүне җайга салучы муниципаль хокукый акт белән айлык бүләкләүгә тиешле елларны хезмәт иткән өчен ай саен өстәп түләү күләме Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 27.04.2018 елдагы “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында”гы №487 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының,

контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативларының III бүлеге 12 пункты 2 подпунктында билгеләнгән күләмнән артык була алмый. Тиешле елларны хезмәт иткән өчен ай саен өстәп өстәмә түләү чыгымнары күләме тиешле вазифа буенча елга өч айлык акчалата бүләкләүдән торган нормативтан арта алмый.

## III. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү

11. Муниципаль хезмәткәрнең акчалата эчтәлеге муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттә биләгән вазифасы нигезендә вазифаи окладтан (алга таба – вазифаи оклад), тиешле елларны хезмәт иткән өчен вазифаи окладка айлык өстәп түләүдән, муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазифаи окладка айлык өстәп түләү, аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләрдән, айлык акчалата бүләкләүләрдән, класслы чин өчен ай саен өстәп түләүдән, ел саен түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән, матди ярдәмнән тора.

12. Муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр түләнә:

1) вазифаи оклад;

Тиешле елларны хезмәт иткән өчен вазифаи окладка түбәндәгеләрдән артмаган айлык өстәп түләү:

| Муниципаль хезмәт стажы | Өстәп түләү күләме |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан артыграк | 20 |

3) муниципаль хезмәтнең аерым шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, эшнең махсус режимы) өчен вазифаи окладка айлык өстәп түләү җирле үзидарә органы җитәкчесе билгеләгән, әмма түбәндәгеләрдән артмаган:

югары муниципаль вазифалар өчен – вазифаи окладның 9 процентыннан;

баш муниципаль вазифалар өчен – вазифаи окладның 7 процентыннан;

әйдәп баручы муниципаль вазифалар өчен – вазифаи окладның 5 процентыннан;

өлкән муниципаль вазифалар өчен - вазифаи окладның 3 процентыннан;

кече муниципаль вазифалар өчен - вазифаи окладның 1 процентыннан;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр үтәгән өчен максималь күләм белән чикләнмәгән, хезмәткә түләү фондының билгеләнгән чикләрендә, түләү тәртибе муниципаль органның функцияләре һәм бурычларны үтәү белән тәэмин ителешне, вазифаи инструкцияне исәпкә алып эш бирүченең вәкиле тарафыннан билгеләнә торган премияләр;

5) вазифаи окладның 1 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү;

6) классны чин өчен айлык өстәп түләү түбәндәгеләрдән артмаган күләмдә:

| Классны чин | Классны чин өчен өстәп түләү күләме (вазифаи окладка процентларда) |
|---|---|
| I классны гамәлдәге муниципаль киңәшче<br>I классны муниципаль киңәшче<br>Муниципаль хезмәтнең I классны киңәшчесе<br>Муниципаль хезмәтнең I классны референты<br>Муниципаль хезмәтнең I классны сәркатибе | 7 |
| II классны гамәлдәге муниципаль киңәшче<br>II классны муниципаль киңәшче<br>Муниципаль хезмәтнең II классны киңәшчесе<br>Муниципаль хезмәтнең II классны референты<br>Муниципаль хезмәтнең II классны сәркатибе | 5 |
| III классны гамәлдәге муниципаль киңәшче<br>III классны муниципаль киңәшче<br>Муниципаль хезмәтнең III классны киңәшчесе<br>Муниципаль хезмәтнең III классны референты<br>Муниципаль хезмәтнең III классны сәркатибе | 3 |

7) ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә, 1,2 вазифаи окладтан артмаган бер тапкыр бирелә торган түләү;

8) хезмәткә түләү фондының билгеләнгән чикләрендә матди ярдәм.

13. Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары җитәкчеләренә акчалата түләү күләме, шәһәр һәм авыл җирлекләре булган һәм хезмәткә түләүнең дүртенче – җиденче, тугызынчы – уникенче төркемнәренә кертелгән муниципаль берәмлекләрдән тыш, тиешле муниципаль берәмлекләрнең башлыкларына акчалата түләүләрнең 0,6 айлык гомуми күләменнән арта алмый.

## IV. Татарстан Республикасында Минзәлә муниципаль районы буенча муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү фондын формалаштыру

14. Минзәлә муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре муниципаль хезмәткәрләренең вазифаи окладларына түләүгә юнәлтелгән акчалар суммасыннан югары хезмәткә түләү фондын формалаштырганда, түләү өчен түбәндәге акчалар күздә тотыла (бер елга исәпләгәндә 12 вазифаи окладтан чыгып):

1) классны чин өчен ай саен өстәп түләү – вазифаи окладның дүрт процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле елларны хезмәт иткән өчен – вазифаи окладның унөч процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәтнең аерым шартлары (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттәге югары казанышлар, эшнең махсус режимы) – вазифаи окладның биш процентыннан артмаган күләмдә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр башкарган өчен премияләр – вазифаи окладның бер процентыннан артмаган күләмдә;

5) ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү – вазифаи окладның ун процентыннан артмаган күләмдә;

6) ай саен акчалата бүләкләү – вазифаи окладның бер процентыннан артмаган күләмдә.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район Башкарма
Комитеты Җитәкчесенең
Карарына Кушымта№1
Дата 24.04.18 № 487

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазифаи окладларын исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары таблицасы

| Вазифалар атамалары | Коэффициентлар сигезенче төркем* |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 2,60 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең Беренче урынбасары | 2,36 |
| Вәкиллекле органның аппарат Җитәкчесе (эшләр белән идарә итүче) | 2,36 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 2,34 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 2,33 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе Урынбасары | 2,14 |
| Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр белән идарә итүче) | 2,19 |
| Башкарма комитет аппараты идарәсе начальнигы | 1,90 |
| Мөстәкыйль бүлек начальнигы (мөдире), Башкарма комитетның башка структур подразделениесе (аппараты) җитәкчесе, контроль орган аудиторы | 1,82 |
| Башкарма комитет аппараты идарәсе начальнигы урынбасары | 1,80 |
| Мөстәкыйль бүлек начальнигы (мөдире) урынбасары, Башкарма комитетның башка структур подразделениесе җитәкчесе урынбасары | 1,59 |
| Муниципаль район башлыгы Ярдәмчесе, Башкарма комитет җитәкчесе Ярдәмчесе, муниципаль район башлыгы киңәшчесе, Башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 1,59 |
| Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек начальнигы | 1,59 |
| Сектор мөдире | 1,47 |
| Баш белгеч | 1,41 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,31 |
| I категорияле белгеч, II категорияле белгеч, белгеч | 1,20 |

*Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең дата 27.04.2018 елдагы “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында”гы № 487 карары белән расланган депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативларының I пункты нигезендә муниципаль берәмлек караган хезмәткә түләү төркеме.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район Башкарма
Комитеты Җитәкчесенең
Карарына Кушымта№2
Дата 27.04.18 № 487

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең вазифаи окладларын исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары таблицасы

| Вазифалар атамалары | Коэффициентлар Алтынчы-җиденче төркемнәр* |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 2,12 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, Вәкиллекле органныңаппарат җитәкчесе (эшләр белән идарә итүче) | 1,97 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 1,97 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе Урынбасары | 1,90 |
| Башкарма комитет аппараты җитәкчесе (эшләр белән идарә итүче) | 1,72 |
| Мөстәкыйль бүлек начальнигы (мөдире), Башкарма комитетның башка структур подразделениесе (аппараты) җитәкчесе | 1,72 |
| Башкарма комитет идарәсе (аппараты) начальнигы урынбасары | 1,49 |
| Баш белгеч | 1,24 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,17 |
| I категорияле белгеч, II категорияле белгеч, белгеч | 1,05 |

*Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең дата 27.04.2018 елдагы "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында"гы № 487 карары белән расланган депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативларының I пункты нигезендә муниципаль берәмлек караган хезмәткә түләү төркеме.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район Башкарма
Комитеты Җитәкчесенең
Карарына Кушымта№3
Дата 27.04.18 № 487

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының авыл җирлекләре муниципаль хезмәткәрләренең вазифаи окладларын исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары таблицасы

| Вазифалар атамасы | Коэффициентлар Уникенче төркем* |
|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 1,37 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (сәркатип) | 1,33 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,11 |
| I категорияле белгеч, II категорияле белгеч, белгеч | 1,00 |

*Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең дата 27.04.2018 елдагы "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында"гы № 487 карары белән расланган депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативларының I пункты нигезендә муниципаль берәмлек караган хезмәткә түләү төркеме.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район Башкарма
Комитеты Җитәкчесенең
Карарына Кушымта№4
Дата 27.04.18 № 487

Минзәлә муниципаль районының контроль-исәп органы рәисенең, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланган вазифаи затларының, депутатларның, муниципаль берәмлек Башлыгының айлык акчалата бүләкләве күләме

| Вазифалар атамалары | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) Сигезенче төркем* |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 29 555 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 26 600 |
| Депутатлар | 14 492 |
| Җирле үзидарәнең сайланган органнары әгъзалары | 12 314 |
| Контроль-исәп органы рәисе | 26 600 |

*Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең дата 27.04.2018 елдагы "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында"гы № 487 карары белән расланган депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативларының I пункты нигезендә муниципаль берәмлек караган хезмәткә түләү төркеме.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район Башкарма
Комитеты Җитәкчесенең
Карарына Кушымта № 5
Дата 27.04.18 № 487

Минзәлә муниципаль районының контроль-исәп органы рәисенең, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының авыл һәм шәһәр җирлекләрендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланган вазифаи затларының, депутатларның, муниципаль берәмлек Башлыгының айлык акчалата бүләкләве күләме

| Вазифалар атамалары | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) | |
|---|---|---|
| | республика һәм район әһәмиятендәге шәһәрләр нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре | шәһәр тибындагы бистә нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләре |
| | Алтынчы төркем | Уникенче төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 26 505 | 15 300 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 23 851 | 11 164 |
| Депутатлар | 12 588 | 11 163 |
| Җирле үзидарәнең сайланган органнары әгъзалары | 11 163 | 11 163 |

*Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең дата 27.04.2018 елдагы “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативлары турында”гы № 487 карары белән расланган депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланган вазифаи затларының, контроль-исәп органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүгә чыгымнар формалаштыру нормативларының I пункты нигезендә муниципаль берәмлек караган хезмәткә түләү төркеме.